| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.07.2017 Казан шәһәре № под-1263/17

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен бер генә башкарма орган буларак коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында

«Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында " 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә бер генә башкарма орган буларак коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибен расларга
2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр Э.Н.Фаттахов

**Расланган**
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 25.07. 2017 под – 1263/17 боерыгы белән

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында граҗданнарны Татарстан Республикасы дәүләт граҗданлык хезмәтенә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенәгә рөхсәт бирү

ТӘРТИБЕ

1. «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында " 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә эшләнгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенәгә рөхсәт бирү тәртибе (алга таба-Тәртип)

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында граҗданнарны Татарстан Республикасы дәүләт граҗданлык хезмәтенә яллаучы вәкиле тарафыннан торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары һәм башка коммерцияле булмаган күчемсез милек хуҗалары ширкәте белән бушлай идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенәгә рөхсәт бирү процедурасын регламентлый

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граҗданлык хезмәтенә яллаучы вәкиле Татарстан Республикасы Премьер - министры урынбасары - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры (алга таба - Премьер-министр урынбасары - министр) булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә кагыла.

2. Коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт турында гариза (алга таба-гариза) әлеге Приказга 1 нче кушымта нигезендә граждан хезмәткәрләре тарафыннан язма рәвештә төзелә.

3. Гражданлык хезмәткәре гаризаны коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка бирә (алга таба - җаваплы зат).

4. Җаваплы зат гариза кергән көнне, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә бирелгән формасы буенча, аны журналга терки.

5. Җаваплы зат гаризаны алдан карауны гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаларны алдан карау барышында җаваплы зат гариза биргән граждан хезмәткәреннән, коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә планлаштырылган катнашу функцияләрен билгели торган язма аңлатмаларны һәм документларны соратып алырга хокуклы.

Нәтиҗә граждан хезмәткәренә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә башкарма орган сыйфатында бушлай катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы тәкъдимне үз эченә алырга тиеш.

6. Гариза теркәлгән көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча җаваплы зат, бәяләмә һәм башка материалларны (булганда), тикшерү өчен, Премьер-министр урынбасары - министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) граҗданлык хезмәткәренә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керергә рөхсәт итү яки рөхсәт бирүдән баш тарту карарын чыгару өчен, гариза тапшыра.

Премьер-министр урынбасары - министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) гариза алган көннән алып ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат карар кабул ителгән көннән соң ике эш көне эчендә Премьер-министр урынбасары – министр (аның вазыйфаларын башкаручы) тарафыннан граждан хезмәткәренә гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа Премьер-министр урынбасары - министр резолюциясе куелган, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Кадрлар сәясәте бүлеге мөһере белән расланган гариза күчермәсен, тапшыра. Премьер-министр урынбасары - министр резолюциясе белән гаризаның оригиналы граждан хезмәткәренең Шәхси эшенә җәлеп ителә.

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен бер генә башкарма орган буларак коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибенә

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрына

_______________________________________________

_______________________________________________

ФИО, вазыйфасы, эш урыны,

_______________________________________________

телефон номеры

Гариза
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә бер генә башкарма орган буларак коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга, яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керергә рөхсәт бирү хакында

Миңа коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керергә
_____________________________________________________________________________

торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек,

_____________________________________________________________________________

дача кулланучылар кооперативлары һәм башка коммерцияле булмаган

_____________________________________________________________________________

күчемсез милек хуҗалары ширкәте

түләүсез нигездә_____________________________________________сыйфатында катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм

__________ ________________ ______________________________

Дата подпись ФИО

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен бер үк башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә эшкә алучы вәкиле белән бушлай катнашырга яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керергә рөхсәт бирү Тщртибенә

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә бер генә башкарма орган буларак коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга, яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керергә рөхсәт бирү хакында Гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | дата | Гариза тапшыручының исеме, фамилиясе, атасының исеме | Гариза тапшыручының имзасы | Гаризаны теркәүченең ФИО | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |